# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**“Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”**
**Татарстан Республикасы Законының 21 һәм 26 статьяларына**
**үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 24 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2010, 3 август, 25 декабрь) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 21 статьяның 4 өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“Муниципаль район һәм муниципаль районның административ үзәге булып торучы җирлек уставларында муниципаль районның җирле администрациясен төзү каралырга мөмкин, аңа күрсәтелгән җирлекнең җирле администрациясе вәкаләтләрен үтәү йөкләнә. Мондый очракта муниципаль районның административ үзәге булып торучы җирлектә җирле администрация төзелми.”;

2) 26 статьяның 4 өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“Әлеге Законның 21 статьясындагы 4 өлешенең өченче абзацында каралган очракта муниципаль районда конкурс комиссиясен оештырганда конкурс комиссиясе әгъзаларының өчтән бере – муниципаль районның вәкиллекле органы,

өчтән бере – муниципаль районның административ үзәге булып торучы җирлекнең вәкиллекле органы, ә өчтән бере Татарстан Республикасы Президенты тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан билгеләнә.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.М. Миңнеханов

Казан, Кремль
2011 елның 19 марты
№ 5-ТРЗ